РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«13» декабрь 2022

№ 267

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 5 маендагы 92 номерлы «Теләче муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кертү турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 465-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 5 маендагы 92 номерлы «Теләче муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кертү турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кертү турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

- 1.2.1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1.3 Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опека яисә попечительлек астында булган, тәрбиягә бала алучы гаиләне дә кертеп яисә Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда патронат гаилә балалары төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмасына өстенлекле рәвештә белем алуга хокуклы,анда абыйсы һәм сеңлесе (тулы һәм тулы булмаган, уллыкка алынган (кызлыкка), балалар, опекуннары (попечительләре), бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) яисә ата-аналар (законлы вәкилләр) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый, «Россия Федерациясендә мәгариф турында»Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев